# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон белән Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең максатлары, бурычлары һәм принциплары билгеләнә, Татарстан Республикасы территориясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме гамәлләрен билгеләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр җайга салына.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) инновация эшчәнлеге – инновация әзерләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле һәм аны яңа товар, хезмәт күрсәтү, җитештерү ысулы (технология) яисә башка иҗтимагый файдалы нәтиҗә рәвешендә гамәлгә ашыруга китереп җиткерүгә юнәлдерелгән эшчәнлек;

2) инновация (инновация продукты):

беренче дәрәҗәдәге – инновация эшчәнлегенең дөньякүләм аналогы булмаган, яңа, югары нәтиҗәле товар, хезмәт күрсәтү, җитештерү ысулы (технология) яисә бүтән иҗтимагый файдалы нәтиҗә рәвешендә практикада реализацияләнгән нәтиҗәсе;

икенче дәрәҗәдәге – яңа товар, хезмәт күрсәтү, җитештерү ысулы (технология) яисә бүтән иҗтимагый файдалы нәтиҗә рәвешендә практикада реализацияләнгән инновация эшчәнлеге нәтиҗәсе һәм (яисә) дөньяда гамәлдә булган, ил базары өчен яңа булган товарларның, хезмәт күрсәтүләрнең, җитештерү ысулларының (технологияләрнең, ноу-хау) яисә иҗтимагый файдалы нәтиҗәләрнең трансфер нәтиҗәләре;

3) инновация проекты – икътисадый нигезләнгән, сроклары, башкаручылары һәм чыгымнары буенча килештерелгән эшләр, оештыру шартлары, финанслау

чыганакларына, җитештерүне оештыру ысулларына, эшләнә һәм эчке һәм тышкы базарларга чыгарыла торган конкуренциягә сәләтле инновациянең техник характеристикаларына һәм куллану үзенчәлекләренә карата таләпләр комплексын билгели торган документ;

4) Татарстан Республикасының инновация сәясәте – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль, икътисадый, мәгълүмати, мәгариф, оештыру һәм башка гамәлләр җыелмасы;

5) инновация инфраструктурасы – инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле эшләр башкаручы һәм хезмәтләр күрсәтүче оешмалар, шулай ук фәнне һәм җитештерүне фәнни-техник комплекслар буларак территориаль интеграцияләү рәвешләре җыелмасы;

6) технополис – фәнне һәм җитештерүне конкуренциягә сәләтле продукция эшләү, гамәлгә кертү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче тикшеренү лабораторияләреннән, мәгариф учреждениеләреннән һәм үзәкләреннән, венчур, гамәлгә кертү, сәнәгать компанияләреннән торучы фәнни-техник комплекс буларак территориаль интеграцияләү рәвеше;

7) инновация фонды – эшчәнлегенең төп төре инновация проектларын һәм инфраструктураны финанслау, шулай ук инновация өлкәсендә бүтән хезмәтләр күрсәтү юлы белән инновация эшчәнлеген үстерүгә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт булган юридик зат;

8) венчур фонды – эшчәнлегенең төп төре финанс чараларын аеруча хәтәр, икътисадый яктан аеруча нәтиҗәле югары технологик инновация проектларына инвестицияләү өчен туплаудан гыйбарәт булган юридик зат;

9) технопарк – эшчәнлегенең төп төре кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмат-консультация хезмәтләре күрсәтүдән, яңа перспектив технологияләрне гамәлгә кертүгә, фәнни сыйдырышлы продукция җитештерүгә һәм инновация профилендәге кече һәм урта предприятиеләрне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне башкару максатларында офис һәм җитештерү мәйданнарын һәм җайланмаларын арендага бирү буенча хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган юридик зат;

10) технологик инкубатор – эшчәнлегенең төп төре инновация эшчәнлеге субъектларына фәнни, җитештерү, кадрлар, юридик, маркетинг, лизинг хезмәтләрен һәм бүтән хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүдән гыйбарәт булган юридик зат;

11) бизнес-инкубатор – яңа төзелгән оешмаларга һәм эш башлап җибәрүче эшкуарларга ярдәм проблемалары белән чикләнгән, аларның идеяләре нигезендә коммерция ягыннан файдалы продуктлар һәм нәтиҗәле җитештерүләр булдыруда ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүче юридик зат.

3 статья. **Инновация эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Инновация эшчәнлеге Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Инновация эшчәнлеге субъектлары**

1. Түбәндәгеләр инновация эшчәнлеге субъектлары була:

1) инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик затлар (Россия Федерациясе гражданнары, гражданлыксыз затлар һәм чит ил гражданнары);

2) инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар (теләсә нинди оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге Россия һәм чит ил оешмалары);

3) инновация эшчәнлеге процессында гамәлгә ашырылучы һәм кулланылучы интеллектуаль милек объектлары милекчеләре;

4) инновация эшчәнлегенә инвестицияләрне гамәлгә ашыручы инвесторлар;

5) инновация инфраструктурасы оешмалары (субъектлары) (технопарклар, технополислар, технологик инкубаторлар, бизнес-инкубаторлар, венчур фондлары, инновация фондлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә инновация инфраструктурасы субъектлары дип танылган бүтән оешмалар);

6) инновация эшчәнлеген координацияләүдә һәм җайга салуда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары.

2. Физик һәм юридик затлар әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру чорына инновация эшчәнлеге субъектлары була.

5 статья. **Инновация эшчәнлеге объектлары**

Түбәндәгеләр инновация эшчәнлеге объектлары була:

1) интеллектуаль эшчәнлекнең техник һәм башка файдалы мәгълүмат булган нәтиҗәләре;

2) инновация продуктын булдыруга бәйле махсус хокуклар объектлары;

3) инновация продуктын булдыруга, үзләштерүгә һәм таратуга бәйле инновация һәм инвестиция проектлары, программалары, эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре;

4) инновация продуктлары;

5) инновация оешмаларының финанс активлары, кыйммәтле кәгазьләре.

6 статья. **Инновация эшчәнлегенең эчтәлеге**

Инновация эшчәнлегенә түбәндәгеләр кертелә:

1) дәүләт идарәсе өлкәсендә яңа идеяләр һәм фәнни белемнәр кертү;

2) икътисадый әйләнештә реализацияләнә торган яңа яисә камилләштерелгән продукция (эш, хезмәт күрсәтү), яңа яисә камилләштерелгән технология булдыруга юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү, проект, эзләнү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкару һәм аларга хезмәт күрсәтү;

3) инновация продуктын эчке һәм дөнья базарларына чыгару эшчәнлеге;

4) яңа яисә камилләштерелгән продукция чыгаруга, яңа яисә камилләштерелгән технология кертүгә технологик яңадан җиһазландыру һәм җитештерүне әзерләү;

5) яңа продукцияләрне (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне), технологияләрне сертификацияләү һәм стандартлаштыру максатында сынаулар үткәрү;

6) яңа яисә камилләштерелгән продукция (эш, хезмәт күрсәтү) җитештерү һәм (яисә) баштагы вакытта инновация проектының чыгымнары капланунын норматив срогына ирешкәнче яңа яисә камилләштерелгән технология куллану;

7) инновация инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

8) законнар белән тыелмаган ысуллар белән үзләштерү һәм гамәлгә ашыру максатында интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм индивидуальләштерү чараларына хокукларны саклау, алу һәм тапшыру;

9) законнар нигезендә инновацияне булдыруга һәм практикага кертүгә юнәлдерелгән бүтән эшчәнлек төрләре.

7 статья. **Татарстан Республикасының инновация сәясәте максаты һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең максаты фәнни-техник потенциалны формалаштыру һәм нәтиҗәле куллану, Татарстан Республикасының мөһим социаль бурычларын гамәлгә ашыру нигезендә Татарстан Республикасының сыйфатлы икътисадый үсешенә һәм икътисадның конкуренциягә сәләтлелегенә ирешүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасының инновация сәясәте түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелә:

1) Татарстан Республикасын инновацион үстерүне норматив һәм хокукый тәэмин итү;

2) инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен киңәйтү, инновация эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән дәүләт ресурсларын куллану нәтиҗәлелеген арттыру;

3) Татарстан Республикасында инновацияләрне булдыруга һәм гамәлгә кертүгә банкларның, бүтән финанс структураларының һәм хосусый инвесторларның финанс капиталын җәлеп итү;

4) инновация юнәлешендә эшләү өчен белгечләр әзерләү системасын формалаштыруга ярдәм итү;

5) Татарстан Республикасының инновация инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү.

8 статья. **Татарстан Республикасының инновация сәясәте принциплары**

Татарстан Республикасының инновация сәясәте түбәндәге принциплардан чыгып формалаша һәм гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасының инновация потенциалын булдыру, саклау, үстерү һәм нәтиҗәле куллану;

2) җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм технологик үсеше дәрәҗәсен, фәнни сыйдырышлы продукциянең конкуренциягә сәләтлелеген, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм экологик иминлекне арттыру өчен инновация эшчәнлегенең өстенлекле әһәмиятен тану;

3) инновация өлкәсендә конкурент механизмның нәтиҗәле эшләве белән берлектә инновация эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырыла торган инновация эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, инновация программаларын һәм проектларын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру механизмнарын сайлауның хәбәрдарлыгы;

5) күп укладлы икътисадны үстерү шартларында инновацияләр базарын үстерү максатында фән, мәгариф һәм җитештерүнең нәтиҗәле үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү өчен инновация, инвестиция, фәнни, фәнни-техник һәм фәнни-мәгариф эшчәнлегенең интеграциясе;

6) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләрендә инновация эшчәнлегенә бирелә торган ресурсларны туплау;

7) инновация эшчәнлеге һәм инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында булдырылган интеллектуаль милек субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан саклау.

9 статья. **Татарстан Республикасының инновация сәясәте эчтәлеге**

1. Татарстан Республикасының инновация сәясәте түбәндәгеләрне билгели:

1) инновация эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен;

2) инновация продуктларының өстенлекле төрләрен;

3) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен һәм аның нигезендә эшләнгән республика максатчан инновация программаларын формалаштыру принципларын һәм аларны гамәлгә ашыру ысулларын;

4) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен һәм аның нигезендә эшләнгән республика максатчан инновация программаларын финанслау механизмнарын һәм чыганакларын.

2. Татарстан Республикасының инновация сәясәте түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен;

2) Татарстан Республикасын инновацион үстерүнең Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген үстерүне чагыштырма бәяләүне уздыруга ярдәм итәрлек ориентирлары системасын үз эченә алган инновация меморандумын;

3) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясе нигезендә эшләнә торган һәм билгеле бер чорга бурычларны, контрольдә тотылучы күрсәткечләрне, аерым гамәлләр исемлеген, инновацион эшкуарлык субъектларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелүче ярдәм чараларын үз эченә алган максатчан инновация программаларын;

4) бюджет финанславының чыганакларын һәм күләмнәрен;

5) Татарстан Республикасының инновация сәясәтен тулаем һәм аның һәр программасы (һәр чарасы) буенча аерым гамәлгә ашыру мониторингы

системасының нигезе булган инновация эшчәнлеге йомгаклары турында дәүләт докладын.

10 статья. **Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясе**

1. Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясе – Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең озак сроклы өстенлекләренә, максатларына һәм бурычларына таяна торган дәүләт идарәсе гамәлләре системасы.

2. Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясе Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак сроклы программалары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

3. Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру срогы тәмамлангач, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы аны гамәлгә ашыру турында йомгаклау хисабын Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыра. Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру турындагы хисап рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясе максатчан инновация программаларын эшләү өчен нигез була.

11 статья. **Татарстан Республикасы инновация меморандумы**

1. Татарстан Республикасы инновация меморандумы – Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен уртача срокка перспективада гамәлгә ашыру механизмын һәм төп макроикътисадый күрсәткечләрне билгели торган, инновация эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен һәм инновация продуктларының өстенлекле төрләрен билгели торган документ.

2. Татарстан Республикасы инновация меморандумы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан өч еллык срокка эшләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

12 статья. **Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турында дәүләт доклады**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы ел саен үткән ел өчен Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турында дәүләт докладын әзерли.

2. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турында дәүләт доклады Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә һәм рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш. Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәгълүматы тыңлана.

13 статья. **Максатчан инновация программалары**

1. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген үстерү максатларында максатчан инновация программалары эшләнә.

2. Максатчан инновация программасы – җитештерү, социаль, икътисадый, оештыру, хуҗалык, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм инновация проектларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән бүтән чараларның ресурслары, башкаручылары һәм башкару сроклары буенча килештерелгән һәм инновация продуктларын үзләштерү һәм тарату бурычларын нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче комплексы.

3. Республика максатчан инновация программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Максатчан инновация программасына кертүгә тәкъдим ителә торган инновация проектларына экспертиза һәм конкурс оештыру һәм үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

14 статья. **Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектларына куела торган төп таләпләр**

Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектлары түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1) инновацияләр булдыруның бердәм максаты белән берләштерелгән тәкъдимнәр булырга;

2) инновация проектын гамәлгә ашыруны техник нигезләү һәм икътисадый максатка ярашлылыгы булырга;

3) инновация проектын икътисадый нигезләү булырга, кире кайтару шартларында дәүләт ярдәме гамәлгә ашырылган очракларда – Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны кире кайтаруны раслаган килеш;

4) продуктның яңа булуын, продукт инновация продукты дип саналган чорны һәм инновация проектының хокукый якланышын раслый торган документлар булырга;

5) инновация проектын гамәлгә ашыруның план-графигы булырга;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органының кертелүче инновация проекты материалларын һәрьяклап бәяли торган уңай эксперт бәяләмәсе булырга.

**15 статья. Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектын бирү тәртибе һәм инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр**

1. Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектын инновация эшчәнлеге субъекты тарафыннан бирү тәртибен башкарма хакимиятнең инновация өлкәсендәге вәкаләтле органы билгели.

2. Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проекты әлеге Законда каралган таләпләргә җавап бирмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы инновация эшчәнлеге субъекты мөрәҗәгать иткәннән соң бер ай эчендә инновация эшчәнлеге субъектына нигезләнгән кире кагуны җибәрә.

3. Түбәндәгеләр инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне кире кагу өчен нигез була:

1) дәүләт ярдәменә дәгъва белдерүче эшчәнлек төренең әлеге Законда билгеләнгән инновация эшчәнлеге төшенчәсенә туры килмәве;

2) кертелгән инновация проектының әлеге Законның 14 статьясы таләпләренә туры килмәве;

3) инновация эшчәнлеге субъектының элегрәк кредит оешмалары тарафыннан бирелгән кредитлар буенча түләнмәгән йә билгеләнгән срокта түләнми торган бурычлары булу;

4) инновация эшчәнлеге субъектының Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча кичектерелгән бурычы булу.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация өлкәсендәге вәкаләтле органының дәүләт ярдәмен күрсәтүне кире кагу турындагы карарына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелә ала.

**16 статья. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы:

1) инновация эшчәнлеге өлкәсендә законнар белән җайга салуны гамәлгә ашыра;

2) законнар нигезендә инновация эшчәнлеге өлкәсендә бүтән вәкаләтләр башкара.

2. Татарстан Республикасы Президенты:

1) Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

2) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен раслый;

3) фән һәм техника өлкәсендә республика премияләрен һәм грантларын раслый;

4) законнар нигезендә инновация эшчәнлеге өлкәсендә бүтән вәкаләтләр башкара.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органын билгели;

2) республика максатчан инновация программасын, Татарстан Республикасы инновация меморандумын һәм Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турындагы дәүләт докладын раслый;

3) инновация инфраструктурасын булдыру һәм үстерү буенча чаралар күрә;

4) законнар нигезендә инновация эшчәнлеге өлкәсендә бүтән вәкаләтләр башкара.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы:

1) Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен, республика максатчан инновация программасын эшли;

2) инновация проектларына экспертиза һәм конкурслар үткәрүне тәэмин итә;

3) Татарстан Республикасы икътисадын инновацион үстерүне формалаштыру принциплары һәм аның перспектив юнәлешләре, өстенлекле программалар һәм проектлар, инновация сәясәтенең макроикътисадый ориентирлары, үстерү институтлары эшчәнлегенең максатчан ориентирлары һәм Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген финанслау чыганаклары булган Татарстан Республикасы инновация меморандумы проектын әзерли;

4) Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге йомгаклары турында дәүләт докладын әзерли;

5) эшчәнлекләренең Татарстан Республикасы инновация меморандумында расланган максатчан ориентирлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә инновация эшчәнлеге субъектлары эшчәнлеге мониторингын гамәлгә ашыра;

6) законнар нигезендә инновация эшчәнлеге өлкәсендә бүтән вәкаләтләр башкара.

17 статья. **Инновация эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу рәвешләре һәм ысуллары**

1. Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган инновация эшчәнлеген җайга салу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәге рәвешләрдән һәм ысуллардан файдалана ала:

1) республика инновация программасын, республиканың бүтән программаларын, шул исәптән инновация эшчәнлеген һәм инновация инфраструктурасын үстерүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм финанслау;

2) инновация проектларын, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм (яисә) инновация эшчәнлеге нәтиҗәләрен булдыру буенча технологик эшләрне финанслау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турындагы законнарда каралган тәртиптә урнаштыру;

3) Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең өстенлекләре нигезендә расланган программалар кысаларындагы инновация эшчәнлеге нәтиҗәсендә булдырылган продуктны сатып алуга дәүләт заказы урнаштыру;

4) инновация эшчәнлеге субъектларына Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән файдалануның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган ташламалы шартларын бирү;

5) инновация һәм венчур фондлары төзү, акчаларны бүтән инновация эшчәнлеге субъектларын булдыруга һәм үстерүгә инвестицияләү, Татарстан Республикасында инновация процессларын үстерү өчен аеруча мөһим булган инновация эшчәнлеге субъектларын булдыруда өлешле катнашу, шул исәптән чит ил инвестицияләрен җәлеп итеп;

6) салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә инновация эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары бирү;

7) иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә инновация өлкәсендә ярдәм күрсәтү;

8) Татарстан Республикасында фәнни-техник эшчәнлекне массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру һәм Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру чараларын гамәлгә ашыру;

9) инновацион активлыкны арттыру, интеллектуаль, фәнни-техник потенциалны ныгыту, Татарстан Республикасында галимнәрне, белгечләрне иҗади активлыкка стимуллаштыру максатларында фән һәм техника өлкәсендә республиканың еллык премияләрен һәм грантларын гамәлгә кую.

2. Инновация эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу, бүтән рәвешләр һәм ысуллар кулланып та, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

18 статья. **Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен күрсәтү рәвешләре һәм ысуллары**

1. Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге төп рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) практикада куллану өчен билгеләнгән яңа яисә камилләштерелгән продукция, яңа яисә камилләштерелгән технология булдыру буенча фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм (яисә) технологик эшләрне финанслау;

2) инновация эшчәнлеге субъектларына Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларын, биләү һәм (яисә) файдалану өчен тапшыру;

3) инновация эшчәнлеге субъектларына җитештерү-технологик ярдәм күрсәтү;

4) махсуслаштырылган һәм консультация хезмәтләрен күрсәтү;

5) инновация эшчәнлеге өлкәсендә белгечләр әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне финанслау.

Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнар нигезендә бүтән рәвешләрдә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме инновация проекты чыгымнары каплану срогына, әмма аны практикага кертү вакытыннан алып җиде елдан да артык булмаган вакытка күрсәтелә.

3. Инновация продуктын үзләштерүгә һәм таратуга дәүләт ярдәме продукт инновация продукты дип саналачак билгеле бер чорга күрсәтелә.

19 статья. **Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен финанслау**

Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шул исәптән законнар белән тыелмаган бүтән акчалар исәбеннән, гамәлгә ашырыла.

20 статья. **Инновация эшчәнлеге субъектларының җаваплылыгы**

Инновация эшчәнлеге субъектлары гамәлдәге законнарны үтәмәгәндә, шулай ук инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бирелә торган акчалардан максатчан файдаланмаган очракта мөлкәти һәм законнарда каралган башка рәвештә җаваплы була.

Инновация эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган бәхәсләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган тәртиптә хәл ителә.

21 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 2 августы
№ 63-ТРЗ